Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.12.2019 ел. Менделеевск ш. № 679

«Киенгоп-Яр Чаллы
«магистраль нефть үткәргеченең сак зонасы»
территориясен файдалануның аерым шартлары зоналары
чикләренә үзгәрешләр кертү турында

«Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә эш итүче ООО «Уральский Кадастровый Центр» директоры Сиражетдинов Илсур Минулла улы йөзендәге мөрәҗәгатен карап, Россия Федерациясе Җир кодексының 56 статьясы нигезендә, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 33 статьясы, Россия Ягулык һәм энергетика министрлыгы тарафыннан 1992 елның 29 апреленнән расланган магистраль торба үткәргечләрне саклау кагыйдәләре, Россия Дәүләт шәһәр техник күзәтчелегенең 1992 елның 22 апрелендәге 9 номерлы карары белән, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2009 елның 17 декабрендәге 22066-ИМ/Д23 номерлы хатын исәпкә алып «Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар турында күчемсез мөлкәт дәүләт кадастрына белешмәләр кертү хакында», линияле объектны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә: «Магистраль нефть үткәргеч лупинг Киенгоп-Яр Чаллы, d=530 мм, 179-180,83 км участогы, 83-206 км участогы. ППМН Киенгоп-Яр Чаллы Тойма елгасы аша 200 кмга, Д-500, лупинг, УРНУ. Реконструкция», Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты,

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. «Киенгоп — Яр Чаллы» МН саклау зонасы» территориясен кулланунын аерым шартлары булган зона чикләренә, «Киенгоп — Яр Чаллы» МН лупингы һәм Кама елгасында (179-202 км, 204-206 км) су асты кичүенең резерв җепләре. 2 нче кишәрлек» зонаның № 16.00.2.558, Менделеевск районы территориясендә урнашкан, кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Саклау зонасы чикләрендә күчемсез милек объектларын куллануда чикләүләр (йөкләмәләр) салырга:

- Россия Федерациясе Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең 22.04.1992 ел, № 9 (Россия Федерациясе Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең 23.11.1994 ел, № 61 карары редакциясендә) һәм Россия ягулык һәм энергетика министрлыгының 29.04.1992 ел, № 61 карары белән расланган магистраль нефть үткәргечләрне саклау кагыйдәләренең 4.3, 4.4 п., 4 п. нигезендә.

3. «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыятенә Удмурт Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастры һәм картография федераль хезмәте идарәсендә күчемсез милекнең дәүләт кадастрына махсус шартлары булган зона турында белешмәләр кертүне тәэмин итәргә (әлеге пунктта күрсәтелгән гамәлләрне тормышка ашырганда, «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыяте ышанычнамәсеннән башка гына эш итәргә хокуклы).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы П.А. Лизуновка йөкләргә.

Җитәкче А.З.Хамматов

Килештерелде:
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Проектлау бүлеге башлыгы МАУ «ТР Менделеевск МР УИИР» Р.З.Хәбиров